**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**«28» март, 2018 ел** **№ 208**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль учреждениеләре тибын үзгәртү юлы белән төзелә торган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының муниципаль казна учреждениеләрен раслау турында» 2017 елның 16 февралендәге 122 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Биектау муниципаль районы Уставына таянып, Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль учреждениеләре тибын үзгәртү юлы белән төзелә торган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының муниципаль казна учреждениеләрен раслау турында» 2017 елның 16 февралендәге 122 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның 4.1 пунктындагы 7 пунктчаны төшереп калдырырга;

1.2. 1 нче кушымтаның 6.6 пунктындагы 1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, федераль законнарда каралган очраклардан һәм оешма идарәсендә катнашу җирле үзидарә органы исеменнән Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган очраклардан тыш, коммерция оешмасы идарәсендә яки коммерцияле булмаган оешма идарәсендә катнашырга (Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләре, сәяси партия идарәсендә, съездда (конференциядә) яисә башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының,

бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтләренең гомуми җыелышында катнашудан тыш);»;

1.3. 2 нче кушымтаның 3.4 пунктындагы 1, 2, 6 һәм 11 пунктчаларны төшереп калдырырга;

1.4. 3 нче кушымтаның 2.4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. мәдәният үсеше һәм халыкка мәдәни хезмәт күрсәтүне тәэмин итү өлешендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы планнарын һәм муниципаль программаларын, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы мәдәниятен үстерү муниципаль программаларын эшләүне гамәлгә ашыра, мәдәният өлкәсендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджеты проектын формалаштыруда һәм аны алга таба корректировкалауда катнаша;»;

2. Әлеге карарны Биектау муниципаль районы сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Г. Кәлимуллин